КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 26 июнь г.Казань № 518

Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы йөзендә «Университет Иннополис» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә куючылар составына керүе турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының Татарстан Республикасының «Университет Иннополис» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә куючылар составына керүе турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасының «Университет Иннополис» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы гамәлгә ашыра.

3. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына:

«Университет Иннополис» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә куючылар составына керергә;

«Университет Иннополис» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә куючылар составына керү белән бәйле чаралар үткәрергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин